ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12.07.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1727**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карары үз көчен югалткан дип тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының норматив-хокукый актларны актуальләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2007 елның 28 ноябрендәге 1775 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Мәгариф» өстенлекле милли проекты буенча Совет төзү һәм эш тәртибе турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев